Укучы фикере

# Өметләр акланырмы?

Газета-журналлар укырга яратсам да, беркайчан редакциягә хат язу белән шөгыльләнгәнем булмады. Ләкин Ф. Ибраһимованың район газетасы битләрендә басылган «Киләчәккә—әйе» дигән язмасы кулга каләм алырга этәрде.

Сүз ТССР халык депутаты Ф. Бәйрәмовага кагылышлы. Сәясәткә аның карашлары миңа республика газеталары һәм телевидение тапшырулары аша таныш. Әйе, ул чын-чынлап татар халкының теле, аның язмышы, киләчәге өчен янып-көя белүче, үз фикерен курыкмый әйтүче, туры сүзле язучы-депутат, һәм ул, Ф. Ибраһимова әйткәнчә, «арзанлы популярлык» казану өчен генә тырышмый. Моның шулай икәне аның чыгышларында ачык чагыла. Әйтик, ул Татарстан суверен республика булгач, аның дәүләт теле булып төп халык теле—татар теле торырга тиешлеген алга сөрә. Һәм монда бернинди ялган яисә ясалмалылык юк. Мәгълүм булганча, ТССРның дәүләт суверенлыгы турында Декларациядә татар һәм рус телләре дәүләт теле итеп игълан ителүе язылган ич. Әмма беренчесе—татар теленең дәүләт теле ролен үтәве гамәлгә ашырылмый әле. Шуның өчен мин болай тәкъдим итәр идем: РСФСРда —рус теле, Казахстанда— казах теле, башка республикаларда башка милләт теле дәүләт теле булсын. Бу уңайдан иптәш Ибраһимовадан түбәндәгене сорыйсы килә: татарлар да руслар төсле үк кеше, әмма нигә әле безнең татар халкыннан югары постларда эшләүчеләребез рус телен өйрәнергә тиеш тә, ә русларга татар телен өйрәнергә ярамый?!

Миңа республикабыз суверенлык алган көннәрдә районыбызда үткәрелгән зур бер киңәшмәдә катнашырга туры килде. Ул көннәрдә республикабызда ике теллелек гамәлгә кертелә икән дигән сүзләр күп йөрде, татарча чыгыш ясарга да мөмкин диделәр. Шуңа ышаныптыр инде, бер иптәш татар телендә чыгыш ясады. Шул вакыт залда шау-шу башланды, әлеге иптәшнең чыгышын рус иптәшләрнең тыңлап утырасылары килмәде.Арада: «Югары белем алып рус телендә чыгыш ясый алмый»,—дип реплика ташлаучылары да табылды. Менә шул вакытта мин үз туган телемнең ни дәрәҗәдә түбән торганын аңлап гарьләндем. Һәм йөрәгеннән татар каны аккан һәрбер иптәш шундый гарьлек кичергәндер дип уйлыйм. Уйламаслык та түгел бит, суверенлык кәгазьдә генә, безгә туган телебездә трибуна артына басып сөйләргә юл һаман юк икән әле. Ә бит рус мәктәбен бетергән рус иптәштән татар телендә чыгыш ясауларын таләп итү турында сүз бармый һәм мондый максат куелмый да. Андый хәлне мин үзем дә күз алдына да китерә алмыйм. Фәүзия Бәйрәмова да «гражданнар сугышына» этәрми, депутатыбызга шундый зур, нигезсез гаеп ташларга һич тә килешми. Ләкин Ф. Ибраһимованың борчылуы бөтенләй нигезсез түгел. Чыгышларыннан аңлашылганча, Ф. Бәйрәмова мөстәкыйль дәүләт идеясен яклый. Моның сәбәбе шунда: ул нигезле рәвештә икеләнә. Союз составында калсак, суверенлык дигән төшенчә кәгазьдә генә калмасмы икән?! Бөтен хикмәт шунда.

Юк, мин рус һәм татар халкын капма-каршы куярга һич җыенмыйм. Мин дә барлык милләтләрнең тигез хокуклы булып бер Союзда яшәүләренә каршы түгел, ләкин һәр кешенең үз гаиләсе булган кебек, һәр милләтнең дә үз-үзен якларлык, үз телен сакларлык нигезе—мөстәкыйль дәүләте булырга тиеш. Бүген сәясәт мәсьәләсендә халкыбызның беренче дәрәҗәдә борчыган проблема шул. Һәм безнең өметләр акланыр микән?

**К. СӘЛИМОВА.**
Норлат шәһәре.



Александр Николаевич Ундалов биографиясе 1978 елдан бирле Ульяновск локомотивлар депосының Норлат филиалы белән бәйле. Нәкъ шул елдан ул машинист ярдәмчесе булып эшли башлады, ә 1983 елдан машинистлык эшенә керешә. Шушы еллар эчендә намуслы хезмәте белән коллективта хөрмәт казанды. Александр Николаевич һәр ай заданиесен уңышлы үтәп килә, ягулыкны янда калдыра. Хәзер ул машинист-инструктор А. П. Веренцов колоннасында хезмәт куя. Төп хезмәте белән бер үк вакытта юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча җәмәгать инспекторы вазифасын да уңышлы алып бара.

Рәсемдә: тепловоз машинисты А. Н. Ундалов.

## Файдасы тими калмас

1 апрельдә Югары Норлат урта мәктәбендә «Көлү көне» үткәрелде. Традицион шаярулар бүген тормышыбызда урын алган һәртөрле мәшәкатьләр, ыгы-зыгыларны икенче планга калдырды, беразга гына булса да яңа сатып алу бәяләре тудырган кәефсезлекне дә шомартты. «Көлү көне»нә һәр класс үзенчәлекле итеп чыгышлар әзерләде. 8 нче класс укучылары кыска, ләкин җанлы, үткен скетчлары белән тамашачыларны туйганчы көлдерделәр. Алтынчы класс укучылары да алардан калышмадылар. Алар, нәниләр күзлегеннән чыгып, өлкәннәргә хас тискәре сыйфатларны тәнкыйтьләделәр. Бу көнне укытучылар, укучылар башкаруында яраткан җырларыбыз яңгырады. «Көлү көне»нә багышланган кичә үткен сатира, тәэсирле юмор, һәртөрле уйлап чыгаруларга бай булды. Ул һичшиксез ял ягыннан да, гыйбрәт ягыннан да файда бирми калмас, шуңа да без мондый кичәне киләчәктә традициягә кертергә ниятлибез.

**Ф. МӨХӘММӘТОВА,**
Югары Норлат авылының XI класс укучысы.

**ЗАМАНА ФАТИРЫ**

Тормышка аек баштан карыйсың да шунда ук үлгәнче эчәсе килә.

x x x

Прораб тормышка планны да җитешсезлекләр белән корган.

x x x

Әгәр кеше үз-үзен алдый икән, аны намуслы дип атап буламы?

x x x

Лирик дөньяны матур итеп күрә, ә калганы—сатирик.

x x x

Әшнәләрне иң элек күтәрәләр, ә аннан соң урынына утырталар.

• *Алар турында сирәк язабыз*

# Партнерлар артык түгел

ОРЛЫКЧЫЛЫК станциясе янәшә-тирәдәге 8 районга хезмәт күрсәтә. Ул—күпьеллык үлән орлыгы үстерүче һәм аны сатып алучы арасында торучы үзенчәлекле оешма. Станция бер яктан үлән орлыгы үстерүче хуҗалыклар белән күбрәк элемтә урнаштырырга тырыша, икенче яктан аны сатып алучылар белән дә ышанычлы партнерлык мөнәсәбәтен өзмәскә тиеш. Ул шушы ике яклы эшлекле мөнәсәбәттән алынган табышка яши. Узган ел станция 7500 центнер күпьеллык үлән орлыгына чистарту (давальческий) үткәрергә тиеш булса, аны 8142 центнер итеп, ягъни 108,6 процентка башкарды. Орлык әзерләү планын 146,5, орлык реализацияләүне 163,8 процентка үтәде.

Станциядә эш ничек оештырыла соң? Алар нигездә һәр районда була торган махсус орлыкчылык хуҗалыклары белән эш итәләр. Спецсемхозлар —станциянең төп подставщиклары, 15 ләп кешене берләштергән коллектив эше шулай ук берничә сезонга-чорга бүленә. Хәзер, мәсәлән, март-апрель айларында алар орлык сату белән мәшгульләр. Гадәттә бу эш өстән җибәрелгән разнарядка буенча башкарыла. Әмма тайпылышлар булмый түгел, еш кына ирекле сату үткәрергә рөхсәт ителә. Шуңа да клиентлар белән партнерлык мөнәсәбәтләренә беркайчан кер кундырмаска тырышалар биредә.

Аннан чәчүлекләргә нигез салу башлана. Биредә төп йөк өлкән агроном Александр Игнатьевич Самсоновка төшә. Ул—тәҗрибәле белгеч, күпьеллык үлән орлыгы үстерү технологиясен әйбәт белә, шуңа аның киңәшләре һәрчак эшлекле була. Участокларны даими контрольдә тоту да аның вазифасына керә. Август аеннан башланган әзерләүләр чорында да аңа мәшәкать байтак төшә. Хәер, бу чорда эш бүлешеп тормыйлар. Бухгалтер Валентина Алексеевна Малинина да турыдан-туры ярдәмгә килә. Ул—бирәдәге иң универсаль белгечләрнең берсе. Озак еллар лаборантка булып эшләгән, шунлыктан Елена Алексеевна Малыгинага якыннан торып ярдәмне ул күрсәтә. Хәер, Елена Алексеевна үзе дә хәзер шактый тәҗрибә туплап өлгергән лаборант инде, 6 нчы елын эшли, Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. Әзерләүләр чоры аларның һәммәсеннән бердәм булып килешеп эшләүне сорый. Өлкән механик Камил Мөнирович Мөлеков та, эшчеләр Надежда Еремеева, Тамара Александровна Григорьева, Надежда Яшмурзина, Наил Шәйдуллин да коллективта ышаныч, хөрмәт казанырга өлгергән эшчеләр. Аларга чистарту сезонында да күп эш төшә. Узган ел орлык хәзерләү өчен бик җайсыз килде. Билгеле инде, бу станция эшенә дә үз тәэсирен ясамый калмады. Әнә хәзер 5 чистарту агрегатының өчесе чимал юклыктан тик тора. Тулы куәтенә эшли алмау, әлбәттә, коллективка бер дә кулай түгел. Бу җәһәттән бәлки берәр уйниятләре бардыр станциянең?

Алдарак спецсемхозлар турында әйтеп узган идек. Чирмешән районының Ленин исемендәге, Яңа Чишмә районының «Кызыл Октябрь» колхозлары—байтактан бу юнәлештә уңышлы эшләп килгән хуҗалыклар. Узган ел «Кызыл Октябрь» 20 тонна кондырак (костер) орлыгы сатты. Ленин исемендәге колхоз исә 100 гектарда кондырак орлыгы үстерә. Беләсезме, нинди табышлы культура ул? Аның 1 центнеры 400 сум, өстәмәләре белән 700гә кадәр басуы ихтимал. Әле телгә алынган хуҗалык элек аның башагын алып орлыкка тапшыра, ә сабак өлешеннән менә дигән печән запасы туплыйлар.

Икеләтә табышка эшләүче хуҗалыкларны тагы да атады станция директоры К. Ш. Шәрапов. Узган ел алар аша 1 миллион 620 мең сумлык товар үткән икән—димәк, исәп-хисап алып барып, алдан күреп эшләүче хуҗалыклар байтак икән. Тик, кызганыч, алар арасыда без район хуҗалыкларын очратмадык.

Ә шул юнәлештә махсуслашкан «Мамык» совхозы кая киткән? Алардан үткән ел 124 центнерга килешү төзелсә дә, орлык тапшырылмаган икән. Сәбәбен ачыклау максаты белән совхозның баш агрономы В. Г. Красновка мөрәҗәгать итәбез.

—Узган елгы һаваны хәтерлисез булыр,—дип аңлатты ул аның сәбәбен гади генә. —Орлыклык участок уңмады, аны сенажга салырга мәҗбүр булдык. Әмма эшне туктатмыйбыз. Быел 60 центнер кандала үләне (донник) орлыгы сатарга килешү төзедек.

Владимир Григорьевич алдагы елларда да бу эш белән мактана алмауларының сәбәбен аңлатып бетерә алмады. Килешүгә килсәк, алар донник түгел, тукранбаш (клевер) орлыгы үстереп сатарга тиеш булуларын да онытып җибәргәннәр бугай. Нәкъ донник орлыгы сатуда һәрчак бар станциядә. Әмма тагы да шикләндергәне—елга сылтау итеп калдырмаслар микән вәгъдәне буш көе?

Авыл хуҗалыгы идарәсе агрономы Х. Халитов та район хуҗалыкларының ни өчен бу юнәлештә эшне җәелдерергә ашыкмаулары турында сорашуыбызга әлләни яңалык өстәмәде.

—Мәшәкатьле эш, четрекле эш. Кайда мәйдан җитми, кайда—шартлар.

Ә безгә калса, күбрәк теләк җитми. Касыйм Шакирович моны районда югары квалификацияле, инициативалы эзләнүчән агрономнар җитмәү белән аңлата. Мөгаен, ул да хаклыдыр. Юкса, исәп-хисап йөртә, киләчәкне алдан күрә белгән хуҗалар аңа битараф калырга тиеш түгелләр. Касыйм Шакирович мисалга шатланып дәлилләр китерә: соңгы вакытта Ульянов исемендәге колхоз һәм «Рассвет» совхозы шул юнәлештә эш алып бара башлаган. Бүгенге экономик торгынлык аларны уйланырга, эзләнергә мәҗбүр иткән икән, аңа ияручеләр табылмый калмас!

Орлыкчылык станциясе үзе дә яшәргә, ныгытырга тырыша. Кул астында зур материаль кыйммәтләр булмаганда да төзү-карау мәшәкатеннән арынмыйлар. Бартер бирегә байтактан үтеп кергән. Складын да төзегәннәр, яңасын да корып яталар, сауна төзелеп килә, ашханә булдыру тәләге белән яналар. Болар, әлбәттә, төп эш белән параллель рәвештә алып барыла. Ә төп хезмәте — күпьеллык үлән орлыгы реализацияләүне гамәлгә ашыручы орлыкчылык станциясенә алдынгы карашлы, ышанычлы партнерлар беркайчан артык түгел.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**

